**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__28___» _____07____ 2026 ел.** **№ ___127___**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 18 ноябрендәге 227 номерлы «2026 елга Азнакай муниципаль районы Физик культура һәм Спорт муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 28 маендагы 158-2 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре товарларына, эшләренә һәм хезмәт күрсәтүләренә бәяләрне, тарифларны билгеләү Тәртибе, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре хезмәтләренә тарифларны (бәяләрне) карау буенча комиссия утырышының 2026 елның 13 июлендәге беркетмәсе нигезендә, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 18 ноябрендәге 227 номерлы «2026 елга Азнакай муниципаль районы Физик культура һәм Спорт муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Юбилейный» спорт мәктәбе (ачык йөзү бассейны) МБУ буенча «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт идарәсе” МКУ халыкка өстәмә түләүле хезмәт күрсәтүгә тарифларны әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына 1 нче
кушымта
«__28___» ____07____2026 №__127____

2026 елга «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт идарәсе» МКУ халыкка өстәмә түләүле хезмәт күрсәтүгә тарифларга үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
"Юбилейный" спорт мәктәбе " МБУ

Ачык йөзү бассейны

| № | Хезмәтнең атамасы | Дүшәмбедән пәнҗешәмгә кадәр түләү | Җомга, шимбә һәм якшәмбе/бәйрәм көннәрендә түләү |
|---|---|---|---|
| 1 | 12 яшькәчә балалар өчен бассейнга керү (олылар белән бергә) | түләүсез | түләүсез |
| 2 | 12 яшьтән 18 яшькәчә яшүсмерләр өчен бассейнга керү | 200 сум | 250 сум |
| 3 | Олылар өчен бассейнга керү (18 яшьтән) | 500 сум | 600 сум |
| 4 | Сауна (7 яшьтән) | 200 сум | 200 сум |

| № | Исеме | Ташламалар |
|---|---|---|
| 1 | Инвалидлар, ятимнәр | түләүсез |
| 2 | Хәрби хезмәттән кайтканнар һәм сугыш ветераннары (таныклык күрсәткәндә) | түләүсез |
| 3 | Азнакай муниципаль районы җирле хәрби идарә кардәшләре балалары («Батыр» картасы булганда һәм 1 якын туган белән) | түләүсез |
| 4 | Пенсионерлар (таныклык күрсәткәндә) | 50% ташлама |
| 5 | 17:00 сәгатьтән соң бассейнга керү | 50% ташлама |